ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Б.Краснаяур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 90

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«04» июнь, 2021 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2019 елның 25 декабрендәге 479 номерлы, 2020 елның 3 августындагы 151 номерлы, 2020 елның 16 ноябрендәге 202 номерлы, 2020 елның 17 декабрендәге 221 номерлы боерыклары керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны җитәкче урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С.Саттаровка йөкләргә.

Җитәкче С.А. Крайнов

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2021 елның 4 июнендәге 90 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 1 ноябрендәге 435 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәккә (алга таба – КФҮ), КФҮнең читтән торып эшләү урыннарына (шәхсән яисә телефон буенча) мөрәҗәгать иткәндә»;

1.4.1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4.1. ТР Дәүләт торак инспекциясенең урнашкан урыны, белешмә телефоны, эш графигы, рәсми сайтының адресы, шулай ук электрон почтасы, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннарының урнашкан урыны һәм эш графигы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырыла.»;

Административ регламентка түбәндәге эчтәлекле 1.4.2 пунктча өстәргә:

1.4.2. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестры» дәүләт мәгълүмат системасында булган белешмәләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүчегә бушлай бирелә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турында мәгълүматтан файдалану мөрәҗәгать итүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең техник чараларына урнаштырылуы лицензия яки түләү алуны, мөрәҗәгать итүчене теркәүне яки авторлаштыруны яки аның тарафыннан персональ белешмәләр тапшыруны таләп итә торган программа тәэминаты хуҗасы белән башка төрле килешүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гына башкарыла.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1.6. Административ регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

аутентификация – аутентификация уздыручыда зат турында булган белешмәләрне чагыштыру һәм аутентификация процедурасы кысаларында аутентификацияли торган билгене (билгеләрне) куллану юлы белән затның идентификаторга

(идентификаторларга) ия булуының хокуклылыгын билгеләү юлы белән идентификаторның (идентификаторларның) аңа каравы буенча затны тикшерүгә кагылышлы чаралар җыелмасы, шуның нәтиҗәсендә зат билгеләнгән дип таныла;

идентификацияләү – зат турында мәгълүматлар билгеләү һәм аларны тикшерү һәм әлеге мәгълүматларны затны билгеләү өчен кирәкле булган мондый зат турындагы белешмәләрнең уникаль билгеләнеше (уникаль билгеләнешләре) белән чагыштыру буенча федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган норматив хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла торган чаралар җыелмасы;

Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы (алга таба – ИАБС) – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада Идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы;

техник хата – дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсенә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр кертүгә нигез булган документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хатасы, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата);

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Административ регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) дигәндә дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать турында сүз бара («Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пункты (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон)). Гаризаларның формалары әлеге Регламентка 1, 2, 3, 4 нче кушымталарда китерелгән.»;

2 бүлектә:

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) лицензия бирү турында (лицензия бирүдән баш тарту турында) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) белдерү (әлеге Регламентның 12 нче, 13 нче кушымталары);

б) үзгәртеп рәсмиләштерү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) белдерү (әлеге Регламентның 14 нче, 15 нче кушымталары);

в) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсен яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә бирү (әлеге Регламентка 8 нче кушымта);

г) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү (әлеге Регламентка 16 нчы кушымта);

д) лицензияне озайту (озайтудан баш тарту) турында белдерү (әлеге Регламенка 17 нче, 18 нче кушымталар);

е) лицензияләр реестрында техник хатаны төзәтү турында белдерү (әлеге Регламентка 19 нчы кушымта);

ж) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (үзгәрешләр кертү мөмкинлегенең булмавы турында) белдерү (әлеге Регламентка 21нче, 22 нче кушымталар).»;

2.4 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензия бирү турында лицензия алырга теләүче затның гаризасын һәм аңа теркәлгән документларны карау – лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган, аңа теркәлә торган документларны (мәгълүматларны) тулы күләмендә кабул иткән көннән башлап 30 (утыз) эш көне;

б) лицензия бирү (лицензия бирүдән баш тарту) турында карар кабул итү – Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенә ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында нигезләнгән тәкъдим алынган көннән башлап 4 (дүрт) эш көне;

в) лицензия бирү турында (лицензия бирүдән баш тарту турында) ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы лицензия комиссиясе карары кабул ителгәннән соң 2 эш көне эчендә чыгарыла;

г) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) карар кабул итү (үзгәртеп кору формасында юридик затны үзгәрткән, аның исемен, урнашкан урыны адресын үзгәрткән очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгән очракта) – ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, аңа теркәлә торган документлар (белешмәләр) тулы күләмендә килгән көннән башлап 10 (ун) эш көне;

д) лицензия бирү турында (лицензия бирүдән баш тарту), лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү (үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту) турында белдерү җибәрү – лицензияне имзалау һәм лицензияләр реестрында теркәү көненнән соң 3 эш көне;

е) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсен яки сорала торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә бирү – тиешле гариза алынган көннән соң 3 эш көне;

ж) лицензиянең гамәлдә булуын туктату һәм лицензияне гамәлдән чыгару – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату

турында гариза; юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан тиешле реестрга юрдик затның эшчәнлеген туктатуы турында яки физик затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турында язу кертелү датасы турында мәгълүмат; лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карары (лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә) ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап – 10 эш көне эчендә;

з) лицензиянең гамәлдә булуын озынайту турында (лицензиянең гамәлдә булуын озынайтудан баш тарту турында) карар кабул итү – ТР Дәүләт торак инспекциясенә гариза алынган датадан башлап 30 календарь көне;

и) техник хатаны төзәтү – хатаны төзәтү турында гариза алынган датадан башлап 5 эш көне эчендә;

к) лицензиат – юридик затның урнашкан урыны, лицензиат – шәхси эшкуарның яшәгән урыны, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны үгәртелгән очракта, географик объектны, урамны, мәйданны яки номерын, шул исәптән почта индексын да, үзгәртеп башка төрле территорияне үзгәртеп атауга бәйле булса, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү – лицензиаттан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә;

л) ТР Дәүләт торак инспекциясендә географик объектны, урамны, мәйданны яки башка төрле территорияне үзгәртеп атау, нумерацияне, шул исәптән почта индексын да үзгәртү турында мәгълүмат булган очракта, лицензияләр реестрына ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан үзгәрешләр кертелүе турында белдерү – лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгән көннән башлап 7 эш көне эчендә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документ (лицензияне бирүдән тыш) мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта буенча яки электрон адреска) җибәрү дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла (лицензияне җибәрүдән тыш).»;

2.5 пунктта

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Лицензия алу өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:

а) лицензия бирү турында гариза, 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1 өлешендә каралган белешмәләрне һәм лицензия алырга теләүче затның 1110 номерлы нигезләмәнең 4 пунктында билгеләнгән лицензия таләпләренә туры килүе турында белешмәләрне (әлеге Регламентка 1 нче кушымта) күрсәтеп;

б) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының (юридик затның бер кулдагы башкарма органының, юридик зат җитәкчесенең яки аның филиалы җитәкчесенең яки шәхси эшкуарның) квалификация аттестаты күчермәсе;

в) лицензия алырга теләгән затның вазыйфаи затының вазыйфага билгеләнүе турында боерык күчермәсе;

г) теркәлә торган документлар исемлеге.

2. Юридик затны үзгәртеп кору формасында үзгәрткән очракларда лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен лицензиат яки аның хокуклы варисы турында 99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 1 өлешендә каралган яңа мәгълүматларны күрсәтеп, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза һәм юридик затларның бердәм дәүләт реестрына тиешле үзгәрешләрне кертү фактын раслый торган документ белешмәләре тапшырыла.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүгә нигез булган очрак (әлеге Регламентка 2 нче кушымта) барлыкка килгән көннән башлап 15 эш көненнән соңга калмыйча ТР Дәүләт торак инспекциясенә тапшырыла.

3. Юридик затның атамасын, урнашкан урынының адресын үзгәрткән очракларда, шулай ук шәхси эшкуарның яшәгән урыны, исеме, фамилиясе һәм (булган очракта) атасының исеме, аның шәхесен таныклый торган документ реквизитлары үзгәртелгән очракларда, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен лицензиат турында яңа мәгълүматларны күрсәтеп, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза һәм юридик затларның бердәм дәүләт реестрына (лицензиат – юридик зат өчен), шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына (лицензиат – шәхси эшкуар өчен) тиешле үзгәрешләр кертелү фактын раслый торган документ белешмәләре тапшырыла (әлеге Регламентка 3 нче кушымта).

4. Конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә яки кабул ителгән карар турында ТР Дәүләт торак инспекциясе акты күчермәсе яисә лицензияләр турындагы мәгълүматлар лицензияләр реестрында булмаган очракта яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкинлеге булмаганда бирелә торган, сорала торган мәгълүматларның булмавы турында белешмә рәвешендә мәгълүматлар алу өчен физик заттан яки юридик заттан мондый мәгълүматларны тапшыру турында гариза бирелә (әлеге Регламентка 7 нче кушымта).

5. 99-ФЗ номерлы Федераль законның 20 статьясының 13 өлешендәге 1 пунктында каралган очракта лицензиянең гамәлдә булуын туктату өчен күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза тапшырыла, анда күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеге фактта туктатылган дата күрсәтелә (әлеге Регламентка 9 нчы кушымта).

6. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту өчен лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза тапшырыла (әлеге Регламентка 10 нчы кушымта).

7. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтү өчен мөрәҗәгать итүче техник хатаны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә (әлеге Регламентка 5 нче кушымта).

8. Лицензиат – юридик затның урнашкан урыны, лицензиат – шәхси эшкуарның яшәгән урыны, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны үгәртелгән очракта, географик объектны, урамны, мәйданны яки номерын, шул исәптән почта индексын да, үзгәртеп башка төрле территорияне үзгәртеп атауга бәйле булса, лицензияләр реестрына үзгәреш

кертү өчен лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза тапшырыла (әлеге Регламентка 11 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану буенча гариза кәгазен мөрәҗәгать итүче ТР Дәүләт торак инспекциясенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе ярдәмендә тапшырылырга (җибәрелергә) тиеш:

шәхсән;

почта аша юллап;

КФҮ аша;

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон формада;

гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән Интернет челтәре аша.

Гаризаны гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон документ рәвешендә тапшырган (җибәргән) очракта, гариза «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләре нигезендә электрон имза белән таныклана.»;

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасына түбәндәге сүзләрне өстәргә;

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон формада күрсәтүгә карата таләпләр турында» 2013 елның 19 мартындагы 236 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2013 елның 19 мартындагы 236 номерлы карары)»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре:

1) лицензия бирүдән түбәндәге нигезләрдә баш тартыла:

а) мөрәҗәгать итүче тапшырган лицензия бирү турындагы гаризада һәм (яки) теркәлә торган документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

б) тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә җавап бирмәвенең билгеләнүе;

в) ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү турында хәбәр алынганнан соң 30 көн эчендә лицензия алырга теләүче тарафыннан тиешенчә рәсмиләштерелгән гаризаның тапшырылмавы;

2) лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән түбәндәге нигезләрдә баш тартыла:

а) мөрәҗәгать итүче тапшырган лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризада һәм (яки) башка документларда (белешмәләрдә) төгәл булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

б) тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә җавап бирмәве билгеләнү;

3) әгәр дәүләт серен яки хезмәт серен саклау мәнфәгатьләрендә Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый белешмәләрдән ирекле файдалану чикләнгән булса, лицензияләрнең бердәм реестрыннан мәгълүмат бирүдән баш тартыла.»;

2.9 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт пошлинасы:

күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия бирү – 30000 сум;

күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү – 5000 сум;

Лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәдәге өземтә өчен түләү – 3000 сум.

Түләү реквизитлары:

Бердәм казна счеты: 40102810445370000079

Керемнәрне исәпкә алу һәм бүлү операциясен гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казна счеты: 03100643000000011100

Банк: Татарстан Республикасы Милли банкы бүлекчәсе – Россия банкы Татарстан Республикасы буенча ФКИ Казан шәһәре

БИК:019205400

Алучының ИНН кыры (61) – 1653015798

Алучының КПП (103) – 165501001

«Алучы» кыры(16) – ТР буенча ФКИ (ТР Финанс министрлыгы, ТР ДТИ)

Шәхси счет ЛБ 007140000-ГосЖилИн) 104 кырында бюджет классификациясенең киләсе коды күрсәтелә:

71410807400011000110 «Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтле органнарының күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләүгә бәйле гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы»

Муниципаль берәмлекләр территорияләренең россиякүләм классификаторы нигезендә ОКТМО.

Исәп-хисап документының түләүнең билгеләнеше кырында (24) түләүнең билгеләнешен идентификацияләү өчен кирәкле булган өстәмә башка мәгълүматны күрсәтергә рөхсәт ителә «Түләүченең статусы» кырында (101): 08 тутыру өчен мәҗбүри.

Лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендәге лицензияләр реестрыннан өземтә түләү алмыйча бирелә.

Түләү кире кайтарылырга тиеш:

тулы күләмдә, әгәр ТР Дәүләт торак инспекциясенә кәгазьдәге өземтә рәвешендә конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында гариза тапшырылмаган булса;

билгеләнгән түләү күләменнән артып киткән күләмдә түләү кертелгән очракта, 3000 сумны арттырган өлешендәге күләмдә;

түләү тулы күләмдә кертелмәгән очракта, кертелгән түләү күләмендә.

Түләүне кире кайтару турында гариза түләү кертелгәннән соң өч ел эчендә тапшырылырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче өземтә алудан баш тарткан очракта, аны бирү өчен кертелгән түләү кире кайтарылмый. Шулай ук түләү лицензия реестрында соратып алына торган мәгълүматлар булмаган очракта да кире кайтарылмый.

Түләүне кире кайтару түләү мөрәҗәгать итүченең анда күрсәтелгән банк реквизитларына, түләүне кире кайтару турында гариза биргән көннән бер ай эчендә күчерелә.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасында өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Лицензияләр реестрыннан кәгазь күчермәне биргән өчен түләү күләмен, аны алу тәртибен, очракларын һәм кире кайтару тәртибен билгеләү турында» 2020 елның 6 ноябрендәге 742 номерлы боерыгы»;

2.14 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү ТР Дәүләт торак инспекциясенең янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционерлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән бинасында һәм бүлмәләрендә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.

Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләрнең дәүләт интеграция системасына тоташтырылган электрон мәгълүмат киоскы (инфомат) белән җиһазландырыла.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озата йөри торган этләрдән файдаланучыларга да, ТР Дәүләт торак инспекциясе биналарыннан, бүлмәләреннән һәм хезмәт күрсәтүдән файдалана алу шартларын тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә каршылыксыз үтеп керү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән каршылыксыз файдалана алу шартлары;

ТР Дәүләт торак инспекциясе территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу, транспортка утыру-төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасында һәм бүлмәләрендә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасыннан, бүлмәләреннән һәм хезмәт күрсәтүләрдән тоткарлыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен кирәкле

җиһазларны һәм мәгълүмат җиһазларын тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле булган, ишетелә һәм күренә торган мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм Брайльның нокталы шрифтлары белән ясалган текстлы һәм тамгалы башка график мәгълүматларны дубльләштерү, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм этнең махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булган очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясе бинасына һәм бүлмәләренә сукырларны озата йөри торган этне кертү;

хезмәт күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.»;

2.15 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының унөченче абзацында «гамәлгә ашырылмый» сүзләрен «гамәлгә ашырыла» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктта:

«Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

а) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталында һәм Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында урнаштырылган мәгълүматны алырга;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан файдаланып тапшырырга;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

д) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә ТР

дәүләт торак инспекциясе, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка формада тапшыру зарурлыгыннан тыш, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша электрон имза белән таныкланган электрон документ формасында бирелә, әгәр бу хакта Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша җибәрелгән гаризада күрсәтелгән булса.

Гаризаны электрон рәвештә формалаштырганда мөрәҗәгать итүчегә түбәндәге мөмкинлекләр тәэмин ителә:

хезмәт күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

гаризаның электрон формасы күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән электрон формага ялгыш керткәндә һәм күрсәткечләрне яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон формага элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

ИАБС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлешендә, ИАБС системасында урнаштырылган һәм Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында басылып чыккан мәгълүматларны файдаланып, мөрәҗәгать итүче тарафыннан белешмәләр кертә башлаганчыга кадәр электрон форма кырларын тутыру;

элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон форманы тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында элек бирелгән гаризаларын карый алу мөмкинлеге.

Гаризаны җибәргән вакытта, мөрәҗәгать итүченең шәхесе исәпкә алу язуын активлаштырганда билгеләнгән булу шарты белән, гади электрон имза кулланыла.

Мөрәҗәгать итүчеләрне кабул итүгә язу (алга таба – язу) Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы, КФҮ контакт-үзәк телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә күпфункцияле үзәктә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге дата башланырга бер тәүлек калгач бетә.

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, мөрәҗәгать итүчегә система аша соралган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

Фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

телефон номерын;

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Алдан язылганда мөрәҗәгать итүче күрсәткән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул иткәндә тапшырылган документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-расламаны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылганда билгеләнгән кабул итү вакыты башланганнан соң 15 минут узу белән, ул килмәгән очракта алдан язылуның гамәлдән чыгарылуы турында мөрәҗәгать итүчегә зарури тәртиптә мәгълүмат җиткерелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тарта ала.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан броньлап кую өчен кирәкле вакыт аралыгы озынлыгын исәпләү өчен кирәкле белешмәләр тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән бүтән гамәлләр кылуны таләп итү тыела.»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон,

2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон;

2013 елның 19 мартындагы 236 номерлы РФ Хөкүмәте карары»;

3 нче бүлектә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча өстәргә:

«10) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү.»;

3.3.1 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.3.1. Лицензия бирү турында гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан исемлеген төзеп кабул ителә, аның күчермәсе, әлеге гаризаны һәм документларны кабул итү көне турында тамгалап, лицензия алырга теләүче затка тапшырыла яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы белән җибәрелә яисә, лицензия алырга теләүче затның ихтыярына карап, ТР Дәүләт торак инспекциясенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында лицензия алырга теләүче затның мондый күчермәне алуын тәэмин итәрлек һәм әлеге документны җиткерүне раслый торган ысул белән җибәрелә.

Лицензия алу өчен лицензия алырга теләүче зат ТР Дәүләт торак инспекциясенә билгеләнгән форма буенча лицензия бирү турында гариза тапшыра, ул юридик затның даими гамәлдә булган башкарма органы җитәкчесе яисә әлеге юридик зат исеменнән эш итү хокукы булган башка зат тарафыннан яки шәхси эшкуар тарафыннан имзалана һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп тапшырыла.

Лицензия бирү турында гаризаны һәм аңа теркәлә торган, Административ регламентта каралган документларны лицензия алырга теләүчеТР Дәүләт торак

инспекциясенә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турындагы Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә электрон документлар (электрон документлар пакеты) формасында җибәрә. Мөрәҗәгать итүчене идентификацияләү һәм аутентификацияләү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм порталыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.»;

3.3.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3.3. ТР Дәүләт торак инспекциясенә әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпәрне бозып рәсмиләштерелгән гариза килгән очракта, җаваплы башкаручы аларны кабул итү көненнән соң 2 эш көне эчендә лицензия алырга теләгән затка, лицензиатка утыз көнлек срокта ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү зарурлыгы турында белдерү (алга таба – җитешсезлекләрне бетерү турында белдерү) бирә яки мондый белдерүне, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган, аңа теркәлә торган документлар тулы күләмендә тапшырылган көннән башлап 2 эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясе әлеге гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны карау яки, кайтару сәбәпләрен мотивлаштырылган рәвештә нигезләп, гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кире кайтару турында карар кабул итә. Әлеге гаризаны һәм теркәлә торган документларны карау турында карар кабул ителгән очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясенең вәкаләтле заты лицензия алырга теләүчегә планнан тыш документар тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проекты әзерли.

ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан лицензия бирү турында яки лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү срогы ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензия бирү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәлә торган, 99-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры килә торган документлар тулы күләмендә алынган көннән башлап исәпләнә. Лицензия алырга теләүче зат тарафыннан, белдерү алынган вакыттан башлап, лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа теркәп тапшырыла торган документлар утыз көнлек срокта тулы күләмдә тапшырылмаган очракта, лицензия бирү турында элек тапшырылган гариза һәм аңа теркәп тапшырыла торган документлар лицензия алырга теләүче затка кире кайтарылырга тиеш.

Лицензия алырга теләүче зат лицензияләр реестрыннан өземтәне электрон формада җибәрү турында сораган очракта, шулай ук лицензия алырга теләүче зат лицензия бирү турындагы гаризаны һәм аңа теркәлә торган, әлеге Регламентта каралган документларны ТР Дәүләт торак инспекциясенә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оеәтыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә электрон документлар формасында җибәргән булса, ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензия алырга теләүче затка әлеге гаризаны һәм аңа теркәлә

торган документларны кабул итү датасы турында тамгаланган, ТР Дәүләт торак инспекциясенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында исемлек күчермәсе яки ачыкланган бозуларны бетерү һәм (яки), мондый белдерүне илтеп җиткерүне һәм аның лицензия алырга теләүче зат тарафыннан алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән, булмаган документларны тапшыру кирәклеге турында белдерү җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: җитешсезлекләрне бетерү турында белдерү, гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кайтару турында белдерү, лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны кабул итү турында белдерү, планнан тыш документар тикшерү уздыру турында боерык (күрсәтмә) проекты.»;

3.5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының лицензияләү комиссиясе ТР Дәүләт торак инспекциясе җибәргән материалларны карый һәм аның эшчәнлеге турындагы Нигезләмәгә туры китереп карар чыгара.

Татарстан Республикасының лицензияләү комиссиясе карары кабул ителгән көненнән башлап 2 эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрелә.

Лицензияләр реестрына язуларны кертү өчен Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карар нигез булып тора.

Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясенең лицензия бирүдән баш тарту турында тәкъдиме әзерләнгән очракта, җаваплы башкаручыга, мондый баш тартуга нигез булып торучы норматив хокукый актларның һәм башка документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама белән, баш тарту сәбәпләренә дәлилле нигезләүне яки, әгәр баш тарту сәбәбе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклануы торса, лицензия алырга теләүчене тикшерү акты реквизитларын күрсәтергә кирәк.

Материалларны карау һәм лицензия бирүдән баш тарту турында карар кабул итү күрсәтелгән материаллар килгән датадан башлап 10 эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясе карары.»;

3.5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.4. Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы лицензияләү комиссиясеннән карар алынгач 2 эш көне эчендә чыгарыла.

Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе тарафыннан имзалана. Лицензия бирү турындагы боерык реквизитлары лицензияләр реестрына кертелә.

Лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгында түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) лицензияләүче органның атамасы – ТР Дәүләт торак инспекциясе;

б) юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы, шул исәптән фирма исеме, оешу-хокук формасы, аның урнашкан урын адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, юридик зат

оештыру турында язуның дәүләт теркәвенә алу номеры;

в) шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта), шәхесен таныклаучы документның исеме һәм реквизитлары, аның яшәү урыны адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның дәүләт теркәү номеры;

г) салым түләүченең идентификация номеры;

д) лицензияләнә торган эшчәнлек төре – күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеге;

е) лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы номеры һәм датасы.

Татарстан Республикасы лицензия комиссиясенең лицензия бирү турында карары кабул ителгән очракта, лицензия бирү турындагы язу лицензияләр реестрына боерык теркәлгән көнне кертелә.

Лицензияне бирү көне булып лицензияләр реестрына лицензия бирү турындагы язуларны кертү көне тора.

Лицензияләр реестрлары электрон рәвештә формалаштырыла һәм аларга язу кертү рәвешендә алып барыла.

Лицензияләр реестрында Лицензияләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләренең 6 пунктында каралган белешмәләр күрсәтелә.

Лицензияләр реестрына кертелгән юридик затка яки шәхси эшкуарга лицензияләр бирү турындагы язуга лицензиянең теркәү номеры булып торган номер бирелә. Лицензиянең теркәү номеры уникаль булып тора. Лицензияләр реестрында бер лицензиатка бирелгән лицензияләрнең теркәлү номеры башка лицензиатка бирелгән лицензияләрнең теркәлү номерын кабатларга тиеш түгел.

Лицензиянең теркәү номеры һәм лицензия бирү датасы; лицензияләүче органның атамасы; лицензиат – юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы, шул исәптән фирма исеме, һәм оешу-хокук формасы, урнашкан урынының адресы, лицензияләнергә тиешле аерым эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары (алга таба – лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны), юридик зат оештыру турындагы язуның дәүләт теркәү номеры, юридик затның телефон номеры һәм (булган очракта) электрон почта адреслары; Россия Федерациясе законнары нигезендә чит ил юридик затлары тарафыннан эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрләрен гамәлгә ашыру мөмкинлеге каралган булса, – чит ил юридик затының тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы, «Россия Федерациясендә чит ил инвестицияләре турында»гы Федераль закон нигезендә аккредитацияләнгән чит ил юридик заты филиалының тулы һәм (булган очракта) кыска атамасы, Россия Федерациясе территориясендә чит ил юридик заты филиалының адресы (урнашкан урыны), аккредитацияләнгән чит ил юридик заты филиаллары, вәкиллекләре дәүләт реестрында чит ил юридик заты филиалын аккредитацияләү турында язу номеры, чит ил юридик заты филиалын аккредитацияләү турындагы язуны аккредитацияләнгән чит ил юридик заты филиаллары, вәкиллекләре дәүләт реестрына кертү датасы, чит ил юридик заты филиалының телефон номеры һәм (булган очракта) электрон почта адреслары; лицензиат – шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның шәхесен таныклый

торган документның исеме һәм реквизитлары, аның яшәгән урын адресы, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алу турындагы язуның дәүләт теркәү номеры, шәхси эшкуарның телефон номеры һәм (булган очракта) электрон почта адреслары; салым түләүченең идентификация номеры; лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшки итә торган башкарыла торган эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне күрсәтеп, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төре; лицензияләүче органның лицензия бирү турындагы боерыгы (күрсәтмәсе) номеры һәм датасы; лицензиянең гамәлдә булу срогын чикләү федераль законнарда каралган очракта, лицензиянең гамәлдә булу срогы ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан лицензияләр реестрына Инспекция тарафыннан лицензия бирү турында карар кабул ителгән көнне кертелә. Мәгълүмат системасы эшендә техник проблемалар килеп чыгуы аркасында күрсәтелгән срокларда белешмәләрне лицензияләр реестрына кертү мөмкинлеге булмаган очракта, тиешле белешмәләр лицензияләр реестрына лицензияләр реестры алып барыла торган мәгълүмат системасының эшчәнлек сәләте торгызылганнан соң, ләкин лицензияләр реестрына белешмәләр кертү өчен тиешле нигез барлыкка килгән көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

Лицензияләр реестрында юридик затка яки шәхси эшкуарга бирелгән һәр лицензиягә карата, Лицензияләр реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләренең 6 пунктында күрсәтелгән белешмәләрдән, лицензияне гамәлдә булган кебек яки гамәлдә булуы туктатылган лицензия кебек яисә лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итә торган, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен гамәлгә ашыруның бер яки берничә урыны буенча башкарыла торган аерым эшләргә, хезмәтләр күрсәтүгә карата өлешчә гамәлдә булуы туктатылган лицензия буларак яки гамәлдә булуы туктатылган лицензия буларак сыйфатлый торган белешмәләр өстәмә чагылдырылырга мөмкин. Мондый белешмәләр лицензияләүче органның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан лицензияләр реестрына мондый үзгәртү өчен нигез булып торган белешмәләр кертелгән көнне үзгәртелергә тиеш.

Лицензиянең теркәү номеры структурасы ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан билгеләнә. Шул ук вакытта ТР ДТИ тарафыннан 2020 елның 1 гыйнварына кадәр бирелгән лицензияләрне теркәү номерлары һәм даталары лицензияләрнең теркәү номерлары һәм лицензияләрне бирү даталары буларак лицензияләр реестрына кертелергә мөмкин.

Лицензияләр реестрына белешмәләр ТР Дәүләт торак инспекциясенең лицензияләр реестрына белешмәләр кертүгә вкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кертелә. Лицензияләр реестрын алып бару лицензияләр реестрына мәгълүматларны керткәндә мондый затны идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрына лицензия бирү турындагы язу кертелгән көннән соң өч эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензиатка, аның ихтыярына карап, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яисә, тапшыру турында белдереп, кәгазь документ рәвешендә заказлы почта юлламасы итеп, лицензия бирелүе турында белдерү җибәрә, шулай ук бу хакта лицензиатка элемтә чаралары аша һәм тиешле мәгълүматны ТР Дәүләт

торак инспекциясенең https://gji.tatarstan.ru рәсми сайтында тиешле мәгълүматны урнаштыру юлы белән дә хәбәр итә.

Лицензия бирү турындагы гаризада лицензияне алырга теләгән зат электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, ТР Дәүләт торак инспекциясе, лицензия бирү турындагы белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, лицензияләр реестрыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, электрон документ формасындагы өземтәне дә лицензиатка бирә (җибәрә).

Лицензия алу турындагы гаризада лицензияне алырга теләгән зат лицензияләр реестрыннан кәгазьдә өземтә алу зарурлыгына күрсәткән булса, ТР Дәүләт торак инспекциясе, лицензия бирү турындагы белдерү җибәрү белән бер үк вакытта, кулга тапшыру турында белдереп, лицензиатка заказлы почта юлламасы итеп лицензияләр реестрыннан өземтә дә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар лицензия комиссиясе карары кабул ителгәннән соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы, лицензия бирү турында лицензияләр реестрына язу кертү.»;

3.5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.5. Лицензия бирүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы Татарстан Республикасы лицензияләү комиссиясеннән карар алынган көннән башлап 2 эш көне эчендә кабул ителә.

Лицензия бирүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы имзаланган көннән башлап 3 эш көне эчендә җаваплы башкаручы лицензия алырга теләүче затка лицензия бирүдән баш тарту турындагы белдерүне тапшыра яки, аның ихтыярына карап, тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында лицензия алырга теләүче затка җибәрә. Баш тарту турында белдерүдә мондый баш тартуга нигез булып торучы норматив хокукый актларның һәм бүтән төрле документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама белән, баш тарту сәбәпләренә дәлилле нигезләү күрсәтелә. Әгәр баш тарту сәбәбе булып тикшерү барышында лицензия алырга теләүченең лицензия таләпләренә туры килмәве ачыклануы торса, тикшерү актының реквизитлары күрсәтелә.

ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензия эшен формалаштыра һәм алып бара, аңа түбәндәге документлар кертелә:

а) лицензия алырга теләүченең лицензия бирү турында гаризасы, лицензиатның гаризасы һәм тиешле гаризага теркәлә торган документлар;

б) лицензия бирү, лицензия бирүдән баш тарту, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында (лицензиянең гамәлдә булу вакытын чикләү федераль законнарда каралган очракта) һәм лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыклары;

в) лицензияләр реестрыннан өземтә күчермәсе;

г) лицензия алырга теләгән затка, лицензиатка карата тикшерүләр билгеләү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыклары, тикшерү актларының, лицензия

таләпләре бозылуның ачыкланган очракларын бетерү турында күрсәтмәләрнең, административ хокук бозулар турында беркетмәләрнең, административ җәза билгеләү турында карарларның һәм лицензия контролен гамәлгә ашыруга бәйле башка документларның күчермәләре;

д) лицензияне гамәлдән чыгару турында суд карарларыннан өземтәләр;

е) лицензияләүне гамәлгә ашыруга бәйле белдерүләрнең һәм башка документларның күчермәләре.

Лицензия эше, мөрәҗәгать итүчегә лицензия бирүгә яки лицензия бирүдән баш тартуга бәйсез рәвештә, мәгълүматның конфиденциальлеген тәэмин итү таләпләрен үтәп, вакыты чикләнмичә ТР Дәүләт торак инспекциясендә сакланырга тиеш.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензия бирүдән баш тарту турында боерык, баш тарту турында белдерү, лицензия эше.»;

3.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6. Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү һәм лицензия бирү (лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту) турында карар кабул итү турында гаризаны һәм теркәп тапшырыла торган документларны карау.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен лицензиат, аның хокуклы варисы яки федераль законда каралган башка зат лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризаны дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә электрон документлар (электрон документлар пакеты) формасында җибәрә ала. Мөрәҗәгать итүчене идентификацияләү һәм аутентификацияләү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталындагы идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм порталыннан файдаланып гамәлгә ашырыла.

Лицензиат, аның хокуклы варисы яки федераль законда каралган башка зат лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турындагы гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенә турыдан-туры тапшырырга яки ТР Дәүләт торак инспекциясе раслый торган форма буенча, тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрергә хокуклы.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза юридик затны үзгәртеп кору, аның атамасын үзгәртү, урнашу урыны адресларын, юридик зат тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен башкару урыннарының адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итә торган, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге үзгәргән очракта бирелә.

Юридик затны үзгәртеп кору формасында үзгәрткән очракта лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү нигезе барлыкка килгән көннән башлап 15 көн узганчы тапшырыла.

Юридик затларны берләштерү формасында үзгәрткән очракта, лицензияне

үзгәртеп рәсмиләштерү фәкать берләшүдә катнашучы һәр юридик затта үзгәртеп корылган юридик затларның хокуклы варисларын дәүләт теркәвенә алу датасына күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия булуы шарты белән генә рөхсәт ителә.»;

3.6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.6.3. Лицензиат тапшырган белешмәләрнең тулы һәм дөрес булуын тикшерүне тәмамлаган датадан башлап 2 эш көне эчендә җаваплы башкаруч лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында (лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында) боерык проектын әзерли.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү өчен боерык проекты, гариза һәм документлар ТР Дәүләт торак инспекциясе башлыгы тарафыннан 2 эш көне эчендә, ләкин лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында яки, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү максатында, лицензиаттан килгән лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза теркәлгән датадан башлап 10 эш көне узганчы карала.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе тарафыннан имзалана һәм лицензияләр реестрында теркәлә. Лицензияләр реестрыннан яңа өземтә ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Лицензия бирү турындагы боерык имзаланган көннән соң өч эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензиатка, аның ихтыярына карап, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында яисә, тапшыру турында белдереп, кәгазь документ рәвешендә заказлы почта юлламасы итеп, лицензия бирелүе турында белдерү җибәрә, шулай ук бу хакта лицензиатка элемтә чаралары аша һәм тиешле мәгълүматны ТР Дәүләт торак инспекциясенең https://gji.tatarstan.ru рәсми сайтында тиешле мәгълүматны урнаштыру юлы белән дә хәбәр итә.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгының (күрсәтмәсенең) номеры һәм датасы, лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү сәбәпләрен күрсәтеп, ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында карар кабул иткән көнне лицензияләр реестрына кертелә. Мәгълүмат системасы эшендә техник проблемалар килеп чыгуы аркасында күрсәтелгән срокларда белешмәләрне лицензияләр реестрына кертү мөмкинлеге булмаган очракта, тиешле белешмәләр лицензияләр реестрына лицензияләр реестры алып барыла торган мәгълүмат системасының эшчәнлек сәләте торгызылганнан соң, ләкин лицензияләр реестрына белешмәләр кертү өчен тиешле нигез барлыкка килгән көннән башлап 3 эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

Лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы проекты әзерләнгән очракта, җаваплы башкаручыга мондый баш тартуга нигез булган норматив хокукый актларның һәм башка документларның конкрет нигезләмәләренә сылтама ясап, баш тарту сәбәпләренә дәлилле нигезләү күрсәтергә кирәк.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияне үзгәртеп рәсмиләштерү турында боерык, лицензияләр реестрында теркәү, лицензияләр реестрыннан өземтә, лицензияне

үзгәртеп рәсмиләштерүдән баш тарту турында боерык, баш тарту турында белдерү.»;

3.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында мәнфәгатьле затның электрон документ формасында бирелгән гаризасы «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә электрон имза белән имзаланырга тиеш.»;

3.7.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Конкрет лицензия турындагы белешмәләр, ихтыярга карап, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә яки ТР Дәүләт торак инспекциясенең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган электрон документ формасында яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк тарафыннан лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә, яисә лицензияләүче органның кабул ителгән карар турындагы акты күчермәсе, яисә лицензияләр турындагы белешмәләр лицензияләр реестрында булмаган очракта яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкинлеге булмаган очракта бирелә торган, соралган белешмәләрнең булмавы турында белешмә рәвешендә мондый белешмәләрне бирү турында гариза алынган вакыттан башлап өч эш көненнән артмаган срокта бирелә. Конкрет лицензия турында мәгълүмат алу рәвеше һәм ысулы мөрәҗәгать итүче тарафыннан мондый мәгълүматларны бирү турындагы гаризада күрсәтелә. Әлеге гаризаның формасы ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан раслана.»;

3.7.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.7.2. Лицензияләр реестрын алып бару лицензияләр реестрыннан өземтәләрне автомат формалаштыруны тәэмин итүче ысул белән гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрыннан өземтәдә 99-ФЗ номерлы Федераль законның 21 статьясындагы 9 өлешендә каралган белешмәләр була.

Лицензияләр реестрыннан өземтәгә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге битнең кодлаштырылган адресын үз эченә алган ике үлчәмле штрих коды язылырга тиеш, анда бирелгән лицензия турындагы мәгълүматларны үз эченә алган лицензияләр реестры язулары урнаштырыла. Лицензияләр реестрыннан өземтәгә салынган ике үлчәмле штрих коды ярдәмендә лицензияләр реестрында үзе турында белешмәләр булган конкрет лицензиягә карата язуларны чагылдыру, шулай ук бирелгән өземтәдә әлеге мәгълүматның актуальлеген раслау да тәэминителергә мөмкин.

Лицензияләр реестрыннан өземтәдә Россия Федерациясе законнары нигезендә ирекле файдалану мөмкинлеге чикләнгән белешмәләр булса, мондый өземтә фәкать әлеге мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге булган затка гына тапшырыла. Шул ук вакытта өземтәдә бирелгән мәгълүматның актуальлеген ике үлчәмле штрих кодыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммункация челтәрендәге битләрнең адресларына күчү юлы белән, турыдан-туры әлеге мәгълүматны бастырып чыгармыйча гына, раслау мөмкинлеге дә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

3.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату.

«Лицензиянең гамәлдә булуын туктату» административ процедурасы

түбәндәгеләргә бәйле рәвештә гамәлгә ашырыла:

а) лицензиат тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза тапшырылуы аркасында;

б) юридик затның эшчәнлеген туктатуы турында (үзгәртеп корылу яки берләшү формасында үзгәртелү очракларыннан тыш, үзгәртелгән юридик затларның хокуклы варисын дәүләт теркәвенә алу датасына берләшүдә катнаша торган һәр юридик затта бер үк эшчәнлек төренә лицензия булганда) яки физик зат тарафыннан шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлек туктатылуы турында юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыра торган федераль башкарма хакимияте органыннан мәгълүмат килүе аркасында;

в) ТР Дәүләт торак инспекциясенә лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә килүе аркасында.

Лицензиянең гамәлдә булуы лицензиатның күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турындагы гаризасы нигезендә лицензияләр реестрына тиешле язу кертелгән көннән башлап, яисә тиешле язулар юридик затларның бердәм дәүләт реестрына яки шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрына кертелгән көннән, яисә лицензияне юкка чыгару турындагы суд карары законлы көченә кергән көненнән башлап туктатыла.

Лицензияне юкка чыгару турында законлы көченә кергән суд карарын гамәлдән чыгару турында суд карары чыгарылган дата ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан лицензияләр реестрына лицензияне юкка чыгару турында элегрәк законлы көченә кергән суд карарын гамәлдән чыгару турындагы суд карары законлы көченә кергән көнне кертелә.»;

3.8.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.1. Җаваплы башкаручы күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында тиешле рәвештә рәсмиләштергән гариза; юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан тиешле реестрга юрдик затның эшчәнлеген туктатуы турында яки физик затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турында язу кертелү датасы турында мәгълүмат; лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карары (лицензияне гамәлдән чыгару турында законлы көченә кергән суд карарыннан өземтә) ТР Дәүләт торак инспекциясенә килгән көннән башлап 10 эш көне эчендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

а) лицензия эшендә лицензиат турында булган белешмәләрне исәпкә алып, тапшырылган белешмәләрнең дөреслеген тикшерә;

б) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проектын рәсмиләштерә;

в) лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белешмәләрне лицензияләр реестрына кертә;

г) лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында, ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы күчермәсен теркәп, лицензиатка хәбәр тапшыра яки, кулга тапшыру турында белдереп, заказлы почта юлламасы итеп җибәрә.

Ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсә-

түдә катнаша торган органнарга җибәрү әлеге Регламентның 3.4 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген туктату турында гариза, лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында боерык һәм лицензиянең гамәлдә булу вакытын туктату турында мөрәҗәгать итүчегә белдерү күчермәсе лицензия эшенә теркәлә.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында лицензияләүче орган боерыгының (күрсәтмәсенең) номеры һәм датасы, лицензиянең гамәлдә булуын туктату нигезе һәм датасы; лицензияне юкка чыгару турында суд карарын чыгару датасы һәм мондый карарның реквизитлары, нигезе ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан лицензияләр реестрына үзе тарафыннан лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында карар кабул ителгән көнне, яисә юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органыннан юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында Россия Федерациясе законнар нигезендә юридик зат тарафыннан эшчәнлекне туктату турында яки физик зат тарафыннан шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлекне туктату турында белешмәләр алынган көнне (үзгәртеп кору яки берләштерү формасында үзгәртүдән тыш, үзгәртелгән юридик затларның хокуклы варисын дәүләт теркәвенә алу датасына юридик затны берләштерүдә катнаша торган һәр затта шул бер үк эшчәнлек төренә лицензия булган очракта), яисә лицензияне юкка чыгару турындагы суд карары законлы көченә кергән көнне кертелә. Мәгълүмат системасы эшендә техник проблемалар килеп чыгуы аркасында күрсәтелгән срокларда белешмәләрне лицензияләр реестрына кертү мөмкинлеге булмаган очракта, тиешле белешмәләр лицензияләр реестрына лицензияләр реестры алып барыла торган мәгълүмат системасының эшчәнлек сәләте торгызылганнан соң, ләкин лицензияләр реестрына белешмәләр кертү өчен тиешле нигез барлыкка килгән көннән башлап 3  эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында белдерү, лицензияләр реестрында теркәү.»;

3.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.9. Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында гаризаны карау.

Лицензиат лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза белән ТР Дәүләт торак инспекциясенә мөрәҗәгать итә.

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын озынайту турында гариза лицензиянең гамәлдә булу вакыты чыккан көнгә 60 эш көне кала һәм 45 эш көне узганчы ТР Дәүләт торак инспекциясенә тапшырыла.

Лицензиянең гамәлдә булу вакытын чикләү федераль законнарда каралган очракта, лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында мәгълүмат ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан  лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту турында үз карары кабул ителгән көнне кертелә. Мәгълүмат системасы эшендә техник проблемалар килеп чыгуы аркасында күрсәтелгән срокларда белешмәләрне лицензияләр реестрына кертү мөмкинлеге булмаган очракта, тиешле белешмәләр лицензияләр реестрына лицензияләр реестры алып барыла торган мәгълүмат системасының

эшчәнлек сәләте торгызылганнан соң, ләкин лицензияләр реестрына белешмәләр кертү өчен тиешле нигез барлыкка килгән көннән башлап 3  эш көненнән дә соңга калмыйча кертелә.»;

3.9.5 пунктта «лицензиянең гамәлдә булуын озайту турында (яисә лицензиянең гамәлдә булуын озайтудан баш тарту турында) боерык,» сүзләреннән соң «лицензияне озайту турында лицензияләр реестрына язу кертү.» сүзләрен өстәргә;

3.10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.10. Техник хатаны төзәтү.

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә хата җибәрелгәнлеге ачыкланса, мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 5 нче кушымтасы нигезендәге форма буенча техник хатаны төзәтү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

Җаваплы башкаручы документларны карый һәм нигезләре булган очракта дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә төзәтмәләр кертү максатында техник хатаны төзәтү турында боерык проектын әзерли.

Техник хатаны төзәтү турында ТР Дәүләт торак инспекциясе боерыгы һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ бер үк вакытта ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе тарафыннан имзалана.

Имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документ лицензиатка (Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры китереп рәсмиләштерелгән ышаныч кәгазе нигезендә вәкаләтле затка) кул куйдыртып тапшырыла яки лицензиатка кулга тапшыру турында белдерүе белән заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә.

Лицензияләр реестрына кертелгән белешмәләрдәге техник хаталар ТР Дәүләт торак инспекциясенең вәкаләтле вазыйфаи заты карары буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хатаны төзәтү турында гариза алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә төзәтелә;

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында боерык, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган, төзәтелгән документ, лицензияләр реестрына яңа язу кертү.»;

3 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 3.11 пунктын өстәргә:

«3.11. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгән очракта лицензиянең теркәү номеры  саклана.

Лицензиат – юридик затның урнашкан урыны, лицензиат – шәхси эшкуарның яшәү урыны, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны үзгәргәндә, географик объектның, урамның, мәйданның яки башка территориянең атамасын үзгәртүгә, нумерацияне, шул исәптән почта индексын үзгәртүгә бәйле булса, тиешле үзгәрешләр ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан лицензияләр реестрына лицензиаттан әлеге үзгәрешләрне раслый торган документларны теркәп, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә кертелә.

Лицензиаттан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза алынган көннән башлап 5 эш көне эчендә ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан лицензиатка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү мөмкинлегенең булмавы турында белдерү җибәрелергә тиеш:

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында лицензиат тапшырган гаризада булган белешмәләр лицензияләр реестрында булган очракта;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тапшырылган гаризада яки аңа теркәлә торган документлар төгәл булмаган яки алган мәгълүмат булган очракта.

ТР Дәүләт торак инспекциясендә географик объектның, урамның, мәйданның яки башка территориянең атамасын үзгәртү, нумерацияне, шул исәптән почта индексын үзгәртү турында мәгълүмат булган очракта, лицензияләүче орган тиешле үзгәрешләрне лицензияләр реестрына лицензиатның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турындагы гаризасыннан башка гына мөстәкыйль кертергә хокуклы. ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензияләр реестрына үзгәрешләрне мөстәкыйль керткән очракта, ТР Дәүләт торак инспекциясе лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгән көннән соң 7 эш көне эчендә лицензиатка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелүе турында белдерү җибәрә (әлеге Регламентка 20 нче кушымта).

ТР Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан әлеге белдерү лицензиатның электрон почта адресына җибәрелә ала, әгәр лицензияләр реестрында мондый адрес турында белешмәләр булса.

Лицензияләр реестрына үзгәреш кертә торган һәр язуга автомат рәвештә үзенең үзгәрү номеры беркетелә һәм һәр шундый язу өчен аны лицензияләр реестрына кертү датасы да күрсәтелә.

Лицензияләр реестрындагы мәгълүматлар үзгәргән очракта, шул исәптән лицензиянең гамәлдә булуы туктатылганда яки лицензияләр юкка чыгарылганда, аңа элегрәк кертелгән белешмәләр аларның актуальлеген югалтуы турында тамгалап саклана (лицензияләр реестрына элегрәк кертелгән белешмәләр үзләренең актуальлеген югалткан очракта).

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында карар, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелүе турында белдерү.»;

5 бүлектә:

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр ТР Дәүләт торак инспекциясе, ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи заты, граждан хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесенә шикаять белдерергә хокуклы. ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Дәүләт хезмәте күрсәтү сәбәпле ТР Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе кабул иткән карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелә.

Күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр күпфункцияле үзәк җитәкчесенә белдерелә, күпфункцияле үзәк җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы затка.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә тапшырыла.»;

5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаның 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү чоры бозылганда. Бу очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт хезмәтләрен яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча функцияләр 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмендә йөкләнгән булса, мөмкин була;

3) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы каралмаган документларны яки мәгълүматларны тапшыру яисә гамәлләр башкару таләп ителгәндә;

4) Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыруы каралган документларны кабул итүдән баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса.Бу очракта мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган күпфункцияле үзәккә тиешле дәүләт хезмәтләрен яки муниципаль хезмәтләрне күрсәтү буенча функцияләр 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тулы күләмендә йөкләнгән булса, мөмкин була;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп ителгәндә;

7) ТР Дәүләт торак инспекциясе, ТР Дәүләт торак инспекциясенең вазыйфаи заты, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмалар яисә аларның хезмәткәрләре дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән срогы

бозылганда. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала;

8) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогы яисә тәртибе бозылганда;

9) дәүләт хезмәте яисә муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен яки муниципаль хезмәтләрне тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала;

10) дәүләт хезмәте яки муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның $7^1$ статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат таләп ителгәндә. Әлеге очракта, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^3$ өлешендә билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт хезмәтләрен тулы күләмендә күрсәтү функциясе йөкләнгән булса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата күпфункцияле үзәккә шикаять белдерелә ала.»;

5.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Шикаять почта буенча, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, ТР Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтыннан (https://gji.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.

Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр почта буенча, «Интернет» челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан яки 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның

сайтаннан файдаланып, тиешенчә, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан җибәрелә (http://www.gosuslugi.ru/) ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә дә кабул итеп алынырга мөмкин.»;

5.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.4. ТР Дәүләт торак инспекциясенә алынган шикаять алынган көненнән соңгы эш көне узганчы теркәлергә тиеш.

Шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соңгы унбиш эш көне эчендә. ТР Дәүләт торак инспекциясенең, күпфункцияле үзәкнең, 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән яисә хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгән очракта яки мондый төзәтмәләрне кертү чоры бозылганда, – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерелә торган ТР Дәүләт торак инспекциясенең, ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), яшәгән урыны турындагы белешмәләр, мөрәҗәгать итүче – юридик затның урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) ТР Дәүләт торак инспекциясенең, ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар хезмәткәренең, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүче ТР Дәүләт торак инспекциясенең, ТР Дәүләт торак инспекциясе вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, күпфункцияле үзәкнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешмалар хезмәткәренең, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезли торган белешмәләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүченең дәлилләрен раслый торган документлар (алар булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.»;

5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә, дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында, ТР Дәүләт торак инспекциясе, күпфункцияле үзәк яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай

ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм, дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында, алга таба мөрәҗәгать итүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.»;

Регламентка түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре.

6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелек тасвирламасы түбәндәге процедураларны эз эченә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат бирү;

2) күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) документлар белән гаризаны ТР Дәүләт торак инспекциясенә җибәрү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү;

6.2. Мөрәҗәгать итүчегә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат бирү.

Мөрәҗәгать итүче күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүдән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен күпфункцияле үзәккә шәхсән, телефон һәм (яисә) электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

